ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктындагы 1 пунктчасына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелә торган үсеше алга киткән территорияләр резидентлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән таләпләргә (алга таба – Таләпләр) туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

2) бишенче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

3) алтынчы абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

4) җиденче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 54-ТРЗ